ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

О внесении изменений в Избирательный кодекс Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 октября 2026 года

Статья 1

Внести в Избирательный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2007, № 5, № 12 (I часть); 2010, № 6 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 12 (I часть); 2012, № 6 (I часть); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 27 (часть I), № 52 (часть I), № 55 (часть I); 2018, № 44 (часть I), № 83 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 28 (часть I); 2020, № 4 (часть I); 2021, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 93 (часть I); 2022, № 77 (часть I); 2023, № 11 (часть I), № 27 (часть I), № 48 (часть I), № 73 (часть I), № 81 (часть I); 2024, № 18 (часть I), № 44 (часть I), № 79 (часть I); 2025, № 33 (часть I), № 85 (часть I); 2026, № 45 (часть I) следующие изменения:

1) в части 5 статьи 12 слова «представительных органов местного самоуправления» заменить словами «представительных органов муниципальных образований»;

2) статью 40 дополнить частью 5^2 следующего содержания:

«5^2. Если решение организующей выборы избирательной комиссии об отказе в заверении списка кандидатов отменено избирательной комиссией в порядке, установленном пунктами 6 и 7 статьи 75 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации», или судом, организующая выборы избирательная комиссия обязана повторно рассмотреть вопрос о заверении списка кандидатов не позднее чем через один день после дня вступления в законную силу соответствующего решения суда или дня принятия соответствующего решения избирательной комиссии, предусмотренного подпунктом «в» пункта 6 статьи 75 Федерального закона «Об основных гарантиях избирательных прав и права на участие в референдуме граждан Российской Федерации».»;

3) статью 47 дополнить частью 2^1 следующего содержания:

«2[1]. В случае, предусмотренном частью 5[2] статьи 40 настоящего Кодекса, при принятии решения о заверении списка кандидатов документы, необходимые для регистрации списка кандидатов, могут быть представлены в соответствующую избирательную комиссию после истечения установленного законом срока их представления, но не позднее чем через пять дней со дня принятия избирательной комиссией соответствующего решения и не позднее чем за пятнадцать дней до дня голосования. В таком случае избирательная комиссия обязана принять решение о регистрации кандидата, списка кандидатов либо об отказе в регистрации в течение срока, указанного в части 2 настоящей статьи, но не позднее чем за восемь дней до дня голосования.»;

4) в части 1 статьи 78 слова «депутатов представительного органа местного самоуправления» заменить словами «депутатов представительного органа муниципального образования»;

5) в части 2 статьи 105 слова «представительный орган местного самоуправления» заменить словами «представительный орган муниципального образования», слова «представительного органа местного самоуправления» заменить словами «представительного органа муниципального образования»;

6) в пункте 20 части 1 статьи 108 слова «депутатов представительного органа местного самоуправления» заменить словами «депутатов представительного органа муниципального образования»;

7) в части 1 статьи 115 слова «депутатов представительного органа местного самоуправления» заменить словами «депутатов представительного органа муниципального образования»;

8) в части 1 статьи 117 слова «в представительном органе местного самоуправления» заменить словами «в представительном органе муниципального образования»;

9) в части 1 статьи 119 слова «депутатов представительного органа местного самоуправления» заменить словами «депутатов представительного органа муниципального образования».

Статья 2

Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 октября 2026 года
№ 67-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 октябрендә
кабул ителде

1 статья

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2025, № 33 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2026, № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 12 статьяның 5 өлешендә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органнары» сүзләрен «муниципаль берәмлекләрнең вәкиллекле органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2) 40 статьяга түбәндәге эчтәлекле 5^2 өлеш өстәргә:

«5^2. Әгәр сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясенең кандидатлар исемлеген таныклаудан баш тарту турында карары сайлау комиссиясе тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 75 статьясындагы 6 һәм 7 пунктларында билгеләнгән тәртиптә яисә суд тарафыннан юкка чыгарылса, сайлауларны оештыручы сайлау комиссиясе судның тиешле карары законлы көченә кергән көннән яисә сайлау комиссиясенең «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 75 статьясындагы 6 пунктының «в» пунктчасында каралган тиешле карары кабул ителгән көннән соң

бер көннән дә соңга калмыйча кандидатлар исемлеген таныклау хакындагы мәсьәләне кабат карарга тиеш.»;

3) 47 статьяга түбәндәге эчтәлекле 2^1 өлеш өстәргә:

«2^1. Әлеге Кодексның 40 статьясындагы 5^2 өлешендә каралган очракта, кандидатлар исемлеген таныклау турында карар кабул ителгәндә, кандидатлар исемлеген теркәү өчен кирәкле документлар аларны тапшыруның законда билгеләнгән срогы тәмамланганнан соң, әмма сайлау комиссиясе тиешле карар кабул иткән көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча һәм тавыш бирү көненә кадәр унбиш көннән дә соңга калмыйча тиешле сайлау комиссиясенә тапшырылырга мөмкин. Мондый очракта сайлау комиссиясе кандидатны, кандидатлар исемлеген теркәү турында йә теркәүдән баш тарту хакында карарны әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән срок эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәр сигез көннән дә соңга калмыйча кабул итәргә тиеш.»;

4) 78 статьяның 1 өлешендә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләренә алмаштырырга;

5) 105 статьяның 2 өлешендә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органы» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы» сүзләренә алмаштырырга;

6) 108 статьяның 1 өлешендәге 20 пунктында «җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләренә алмаштырырга;

7) 115 статьяның 1 өлешендә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләренә алмаштырырга;

8) 117 статьяның 1 өлешендә «Җирле үзидарәнең вәкиллекле органында» сүзләрен «Муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органында» сүзләренә алмаштырырга;

9) 119 статьяның 1 өлешендә «җирле үзидарәнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләрен «муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын» сүзләренә алмаштырырга.

2 статья

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 29 октябрь
№ 67-ТРЗ